**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Сөйки авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 7 июне** **№ 78**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 2013 елның 18 декабрендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген төзү һәм җирләреннән файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 89 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 2013 елның 18 декабрендәге 89 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген төзү һәм җирләреннән файдалану кагыйдәләренә түбәндәге узгәрешләр кертергә:

1.1. 14 статьда:

а) өченче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты әлеге статьяның нигезләмәләрен исәпкә алып Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезендә иҗтимагый фикер алышуында яки гавами тыңлауларында каралырга тиеш.

Җир кишәрлегенең яки капиталь төзелеш объектының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төре әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынты күрсәтергә мөмкин очракта иҗтимагый фикер алышу яки гавами тыңлаулар әлеге тискәре йогынтыга дучар булган җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре катнашында үткәрелә.”;

б) 4 пунктта “Комиссия” сүзен “иҗтимагый фикер алышу яки гавами тыңлаулар оештыручысы” сүзләренә алмаштырырга, “бирү сораулары турында гавами тыңлаулар” сүзләрен “бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышуы яки гавами тыңлаулар” сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

г) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Иҗтимагый фикер алышу яки гавами тыңлаулар үткәрү вакыты “Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге яшәүчеләренә хәбәр итү көненнән иҗтимагый фикер алышу яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгару көненә кадәр “Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы һәм (яки) “Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советынын норматив-хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан артык булмаска тиеш.”;

д) 8 пунктта “соравы буенча гавами тыңлаулар” сузләрен “карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышуы яки гавами тыңлаулар” сүзләренә алмаштырарга;

е) 10 пунктта “бирү турында сораулары буенча гавами тыңлаулар” сүзләрен “бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышу яки гавами тыңлаулар” сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 30 статьяның 10 пунктында “гавами тынңлаулар” сүзләрен “иҗтимагый фикер алышу яки гавами тыңлаулар” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Красноармейская ур., авыл үзәге;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Колхоз ур., йорт 16а, китапханә бинасы,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы,
“Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге Советы рәисе В.П. Никитин